ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13 апрель, 2022 ел № 14/8

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, шәһәр Уставының 71 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясесенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
14/8 Карарына
кушымта
13 апрель, 2022 ел

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1. Муниципаль берәмлек территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, шәһәр Уставының 71 статьясы нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Нигезләмә гражданнар җыенын җыю, гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү, гражданнар җыенын уздыру процедурасы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены тарафыннан карар кабул итү тәртибен билгели.

Гражданнар җыены үткәрелә торган шәһәр территориясенең чикләре шәһәр территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләрнең җирле әһәмияттәге тиешле мәсьәләне хәл итүдә мәнфәгатьләре бердәмлеге критериеннән чыгып билгеләнә.

Гражданнар җыены үткәрелә торган шәһәр территориясе өлеше чикләрен билгеләү критерийлары:

1) торак йортлар төркеменең бердәм территориаль - пространство бөтенлеге, күпфатирлы торак йорт, торак микрорайон, гражданнарның башка яшәү территориясе;

2) әлеге пунктның 1 пунктчасында күрсәтелгән территориядә кимендә ун кеше яшәве.

3. Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәүче гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү максатында бер тапкыр бирелә торган түләүләре аңлашыла.

Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең гражданнар җыены үткәрелә торган өлешендәге барлык халык өчен бертигез күләмдә абсолют зурлыкта билгеләнә, моңа саны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендәге халыкның 30 процентыннан артмый торган аерым категорияләре керми, анда гражданнар җыены үткәрелә һәм үзара салым турындагы мәсьәләне хәл иткәндә түләүләр күләме кимергә мөмкин.

4. Бер тапкыр түләнә торган түләүне түләүче булып яшәү урыны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенен гражданнар җыены үткәрелә торган өлешендә урнашкан, 18 яшькә җиткән граждан исәпләнә.

5. Россия Федерациясе гражданнары җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына бәйсез рәвештә гражданнар җыенында катнашуга тигез хокукка ия.

Гражданнар җыенында катнашу хокукына 18 яшькә җиткән, сайлау хокукына ия булган, яшәү урыны буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә теркәлгән ия (алга таба - гражданнар җыенында катнашучылар).

Һәр граждан бер тавышка ия. Гражданнар җыенында катнашу – ирекле. Җыенда гражданнарның катнашуына яисә катнашмавына, шулай ук аларның ирекле ихтыяр белдерүләренә берәү дә мәҗбүри йогынты ясарга хокуклы түгел.

6. Муниципаль берәмлек территориясенең бер өлешендә халык җыенында катнашу хокукына ия гражданнарның яртысыннан артыгы катнашканда җыен хокуклы санала.

7. Кирәк булганда, җыенны әзерләүгә һәм уздыруга бәйле чыгымнар муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән башкарыла.

## 2. Гражданнар җыенын җыю тәртибе

8. Әлеге Нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән мәсьәләне хәл итү өчен үткәрелә торган гражданнар җыенын җыю инициативасы белән муниципаль берәмлек территориясенең бер өлешендә яшәүче, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия булган, кимендә ун кешедән торган (алга таба - гражданнар җыены инициаторы) инициатив төркем чыгарга мөмкин.

9. Халыкның инициативасы әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә имза кәгазьләре рәвешендә рәсмиләштерелергә тиеш, аларда түбәндәгеләр күрсәтелә:

- гражданнар җыенына кертелә торган мәсьәләләр;
- гражданнар җыенын үткәрүнең тәкъдим ителә торган сроклары;
- гражданнар җыенын чакыру турындагы инициативаны хуплаган һәр гражданның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясе һәм номеры, яшәү урынының адресы, имзасы һәм имза кую датасы.

10. Гражданнар җыенын уздыру инициативасын хуплап җыелырга тиешле имзалар саны муниципаль берәмлек территориясенең бер өлешендә яшәү урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия гражданнар санының 5 процентын тәшкил итә, ләкин ун имзадан да ким була алмый.

11. Имза кәгазьләре имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан таныклау датасын, фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, паспортының яисә аны алмаштыручы документының номерын һәм сериясен, яшәү урыны адресын күрсәтеп таныклана һәм шәһәр Хакименә җибәрелә.

## 2. Гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул итү тәртибе

12. Инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар җыены әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар кергән көннән алып 30 көн

эчендә Яр Чаллы шәһәре Хаикменең хокукый акты формасында кабул ителә торган гражданнар җыены турындагы карар белән билгеләнә.

Гражданнар җыены турындагы карарда гражданнар җыенын уздыру инициаторы, гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә, гражданнар җыенын уздыру датасы (гражданнар җыены берничә этапта уздырганда, һәр этапның уздыру датасы күрсәтелә), гражданнар җыенын уздыру вакыты, урыны, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия кешеләр исемлеген төзергә вәкаләтле зат күрсәтелә.

13. Шәһәр Хакиме гражданнар җыенын үткәрүдән баш тарту турында карар кабул иткәндә, гражданнар җыены инициаторына хат җибәрелә, анда әлеге Нигезләмәнең 15 пункты нигезендә гражданнар җыенын үткәрүдән баш тарту нигезләре күрсәтелә. Гражданнар җыенын үткәрүдән баш тарту турындагы хат шәһәр Хакиме тарафыннан карар кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә имза кәгазьләрендә күрсәтелгән имзаларны җыючы зат адресы буенча җибәрелә.

14. Гражданнар җыенын үткәрү турындагы яисә аны уздырудан баш тарту турындагы карар әлеге Нигезләмәнең 9 пунктында күрсәтелгән таләпләр нигезендә әзерләнгән һәм рәсмиләштерелгән имза кәгазьләре кергән көннән соң 30 көн эчендә кабул ителергә тиеш.

15. Гражданнар җыенын үткәрүдән баш тарту турындагы карар шәһәр Хакиме тарафыннан түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) гражданнар җыенын җыю турындагы инициативаны хуплаган гражданнарның имзаларын тапшырмау;

2) инициативаны күрсәтү өчен гражданнар имзаларының саны җитәрлек булмау;

3) имза кәгазьләрен рәсмиләштерүгә карата әлеге Нигезләмәнең 10 пунктында күрсәтелгән таләпләнең бозылуы;

4) гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә җирле билгеләнештәге мәсьәләләргә кагылмаса;

5) гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәлә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарына, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актларына каршы килсә.

16. Гражданнар җыенын үткәрү турындагы яки аны уздырудан баш тарту турындагы карар аны уздыру көненә кадәр ун көннән дә соңга калмыйча рәсми рәвештә басылып чыгарга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында (www.nabchelny.ru) урнаштырылырга тиеш.

17. Яр Чаллы шәһәре халкына гражданнар җыенын уздыру турында хәбәр итү көне булып гражданнарның җыенын уздыру турында карарны ин беренче булып беренче бастырып чыгару чыганагы яисә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында чыгару датасы санала.

## 4. Гражданнар җыенын оештыру тәртибе

18. Гражданнар җыенын оештыру һәм үткәрү өчен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәүчеләрнең инициатив төркеме кимендә биш кешедән торган Комиссия төзи. Комиссия составына рәис, секретарь, комиссия әгъзалары керә.

19. Гражданнар җыенын үткәрергә әзерләнгәндә Комиссия

1) гражданнар җыенында катнашучыларны теркәүне гамәлгә ашыра;

2) әлеге Нигезләмәнең 2 нче кушымтасы формасы нигезендә гражданнар җыены үткәрелә торган территориядә яшәүче, гражданнар җыенында катнашу хокукына ия гражданнар җыенында катнашучылар исемлеген төзи;

3) тавыш бирүнең мондый төреннән файдаланганда, әлеге Нигезләмәнең 3 нче кушымтасы нигезендә тавыш бирү өчен бюллетеньнәр әзерләүне тәэмин итә;

4) гражданнар җыенын уздыру өчен бина бирүне тәэмин итә, ә бина бирү мөмкин булмаган очракта - ачык урында гражданнар җыенын уздыруны оештыра.

20. Комиссия мөрәҗәгате буенча, кирәк булган очракта, Башкарма комитет тарафыннан гражданнар җыенын уздыру өчен бина бирелергә мөмкин, шулай ук тавыш бирү өчен бюллетеньнәр дә әзерләнергә мөмкин.

## 5. Гражданнар җыенын үткәрү тәртибе

21. Җыенга килгән гражданнарга, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең гражданнар җыенында катнашучылар исемлегенә кертелгән һәм җыенда катнашу хокукына ия булган очракта, җыенда катнашу рөхсәт ителә.

22. Җыен башланганчы Комиссия әгъзалары тарафыннан анда катнашучыларны җыенда катнашучылар исемлеге нигезендә теркәү уздырыла.

23. Сайлау хокукына ия гражданнар җыенында катнашучылар исемлегендә төгәлсезлекләр ачыкланган очракта, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең җыен үткәрелә торган өлешендә яшәүче җыенда катнашучылар исемлегендә теркәлергә һәм җыенга кертелергә тиеш.

24. Җыенны Комиссия рәисе (алга таба - Рәис) алып бара. Рәис гражданнар җыенын уздыруны оештыра, тәртип урнаштыра, чыгыш ясау өчен сүз бирә.

## 6. Гражданнар җыенында карар кабул итү тәртибе

25. Гражданнар җыенының карары ачык тавыш бирү яисә тавыш бирү бюллетеньнәрен кулланып тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

26. Тавыш бирү һәр мәсьәлә буенча аерым уздырыла. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмәгә кертелә, ул рәис һәм секретарь тарафыннан имзалана.

Үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының карары, гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан күбрәге аның өчен тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.

Катнашучыларның яртысыннан кимрәге катнашкан булса, гражданнар җыены узмаган дип танылa.

27. Гражданнар җыенының карары әлеге Нигезләмәгә 4 нче, 5 нче кушымтадагы форма нигезендә гражданнар җыенының беркетмәсе рәвешендә

рәсмиләштерелә. Гражданнар җыены беркетмәсенә гражданнар җыенында катнашу хокукына ия булган, гражданнар җыенында катнашкан, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәүчеләр исемлеге кушып бирелә.

Гражданнар җыены беркетмәләре аны уздырганнан соң ун эш көне эчендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына (алга таба - Башкарма комитет) саклауга тапшырыла.

28. Җыенда кабул ителгән карар рәсми бастырып чыгарылырга һәм Яр Чаллы әһәренең «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

29. Гражданнар җыенында катнашучыларның шәхси мәгълүматларын эшкәртү «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

30. Гражданнар җыенында катнашу хокукына ия Яр Чаллы шәһәре халкының бер үк вакытта бергә җыелу мөмкинлеге булмаган очракта, гражданнар җыены гражданнар җыенын уздыру турында карар кабул ителгән көннән бер айдан да артык булмаган вакытта этаплап уздырыла.

31. Гражданнар җыенының һәр этабы гражданнар җыенын уздыру өчен әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә уздырыла. Гражданнар җыены этаплары саны чикләнми һәм гражданнар җыенында катнашу хокукына ия булган, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә яшәүчеләр саныннан чыгып билгеләнә. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендәге халыкның яртысыннан күбрәге катнашканчы гражданнар җыены этаплап үткәрелә.

32. Элек гражданнар җыенында катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмыйлар.

33. Гражданнар җыены этаплап уздырылган очракта, гражданнар җыенының һәр этабында тавыш бирү нәтиҗәләре кушыла.

34. Гражданнар җыенында кабул ителгән карарлар Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә башкарылырга тиеш. Гражданнар җыены карарын гамәлгә ашыру өчен муниципаль хокукый акт чыгару таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән хокукый актны кабул итү кирә торган җирле үзидарә органы карар кабул ителгән көннән алып 30 көн эчендә тиешле хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү вакытын билгеләргә тиеш. Күрсәтелгән срок өч айдан да артмаска тиеш.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

## ИМЗА КӘГАЗЕ

Без, түбәндә имза куючылар,

______________________________________________________________

(гражданнар җыенын уздыру сроклары)

______________________________________________________________

мәсьәләсе бенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе өлешендә гражданнар җыены үткәрү инициативасын хуплыйбыз

Бер тапкыр түләнә торган түләү күләме _______________________________

Аерым категория гражданнар өчен түләү күләме _____________

| № | Фамилия, исем, атасының исеме | Туган көне | Яшәү урыны буенча адресы | Паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясе, номеры | Имза кую датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Гражданнарның шәхси мәгълүматларын җыю, эшкәртү, файдалану һәм саклау «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Имза кәгазен таныклыйм __________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне

______________________________________________________________

яшәү урыны, паспортының сериясе һәм номеры яисә аны алмаштыручы документның номеры,

______________________________________________________________

имзалар җыюны гамәлгә ашыручы)

_______________________

(имза һәм дата)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

Гражданнар җыенында катнашучылар исемлеге

___________________________________

( Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе өлешенең исеме),
___ елның ______________ гражданнар җыенында катнашу хокукы булган

| № | Фамилия, исем, атасының исеме | Туган көне | Яшәү урыны буенча адресы | Паспортының яисә аны алмаштыручы документының сериясе, номеры | Имза кую датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

Гражданнарның шәхси мәгълүматларын җыю, эшкәртү, файдалану һәм саклау «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

Гражданнар җыены рәисе ___________ ________________________
(имзаның аңлатмасы)

Гражданнар җыены секретаре _ ___________ ______
(имзаның аңлатмасы)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

**Гражданнар җыенында тавыш бирү өчен**
**БЮЛЛЕТЕНЬ**

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлек территориясендә
20__ ел, __________________

Тавыш бирү бюллетенен тутыру тәртибен аңлату

Һәр сорауга каршы бер буш квадратта теләсә нинди тамга куегыз (әйе яки юк).

Мәсьәлә каршында (әйе яки юк) бер квадраттан артык квадратка теләсә нинди билге куелган яисә бер билге дә куелмаган бюллетень әлеге мәсьәлә буенча тавышларны санаганда исәпкә алынмый.

| Сорау тәртибе | Сорауның формулировкасы | Җавап | |
|---|---|---|---|
| | | ӘЙЕ | ЮК |
| | | | |
| | | | |

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ БЕРКЕТМӘСЕ**

______________________________________________________
(торак пункт исеме)

20___ ел, ______________________ 00 сәгать, 00 минут № _________

Катнаштылар __________________________________________ кеше
(сайлау хокукына ия гражданнарның гомуми саны, катнашучылар саны)
Гражданнар җыенында рәислек итүче
_____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Гражданнар җыены секретаре ____________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

**КӨН ТӘРТИБЕ**

1.

2.

**ҖЫЕНДА РӘИСЛЕК ИТҮЧЕ САЙЛАНА**

1. ________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Хуплыйм» _________ кеше
«Каршы» _________ кеше
«Тавыш бирүдән тыелам» _________ кеше

**ҖЫЕН СЕКРЕТАРЕ САЙЛАНА**

2. ________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)

Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Хуплыйм» _________ кеше
«Каршы» _________ кеше
«Тавыш бирүдән тыелам» _________ кеше

## ҖЫЕННЫҢ САНАУ КОМИССИЯСЕ САЙЛАНА:

Санау комиссиясе рәисе ________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)
Санау комиссиясе әгъзалары 1. ____________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)
2. ____________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазыйфасы)
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Хуплыйм» _________ кеше
«Каршы» ________ кеше
«Тавыш бирүдән тыелам» ________ кеше

**Рәислек итүче:** Тавыш бирү ачык була (тавыш бирү бюллетеньнәрен кулланып)
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Хуплыйм» _________ кеше
«Каршы» ________ кеше
«Тавыш бирүдән тыелам» ________ кеше

## КӨН ТӘРТИБЕ БУЕНЧА ЭШ:

**Беренче сорау буенча тыңладылар:**
______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (кушымтада бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1.
________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (кушымтада бирелә)
һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Хуплыйм» _________ кеше
«Каршы» ________ кеше
«Тавыш бирүдән тыелам» ________ кеше

Карар _________________________________
(кабул ителгән/кабул ителмәгән)
**Икенче сорау буенча тыңладылар:**
______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (кушымтада бирелә)

**Чыгыш ясадылар:** 1.
___________________________________________________________

(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
(чыгышның кыскача язмасы яисә доклад тексты (кушымтада бирелә)
һ.б. (чыгыш ясаучы гражданнар саны буенча)

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕЛӘР:** (карарның эчтәлеге)
Тавыш бирү нәтиҗәләре:
«Хуплыйм» _________ кеше
«Каршы» ________ кеше
«Тавыш бирүдән тыелам» ________ кеше

Карар ____________________________________
(кабул ителгән/кабул ителмәгән)

Гражданнар җыенында рәислек итүче ___________ ____________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)
Гражданнар җыены секретаре _ ____________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясенең бер өлешендә гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә
5нче кушымта

**ҖЫЕННЫҢ ҮТКӘРЕЛГӘН ЭТАПЛАРЫ НӘТИҖӘЛӘРЕ БУЕНЧА ЙОМГАКЛАУ БЕРКЕТМӘСЕ**

______________________________________________________________

(торак пункт исеме)

20___ ел, ______________________ 00 сәгать, 00 минут № __________

20 ___ ел, _____ гражданнар җыенының беренче этабы беркетмәсе (рәислек итүче Ф.И.А.и.), 20 ___ ел, _____ гражданнар җыенының икенче этабы беркетмәсе (рәислек Ф.И.А.и.) һ.б. нигезендә, гражданнарның җыеннары түбәндәге сорау (сораулар) буенча этаплап үткәрелде ) ______________________________________
______________________________________________________________

1. Ачык тавыш бирү формасын кулланып, җыенның уздырылган этаплары саны - _________;
2. Этаплап үткәрелгән халык җыеннарының тапшырылган беркетмәләре саны________;
3. Җыен уздыру өчен билгеләнгән һәм алар эшендә катнашырга хокукы булган территориядә яшәүче гражданнарның гомуми саны ________;
4. Сайлау хокукына ия булган һәм җыен этапларында катнашкан гражданнарның гомуми саны _________________.

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕЛӘР: (карарның эчтәлеге)**

- Гражданнар җыены этапларында кертелгән сорауны (сорауларны) «Хуплыйм» дип бирелгән тавышларның гомуми саны_______
«Каршы» дип бирелгән тавышларның гомуми саны __________.

**КАРАР: кабул ителде (кабул ителмәде, сәбәбен күрсәтеп)**

Рәислек итүче

(имза) (имзаның аңлатмасы)

Секретарь ____ ____________________

(имза) (имзаның аңлатмасы)